ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.05.2023 г. № 107

2023 елга Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәрендә торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын ачыклау тәртибен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы боерыгының 4.1 пунктына таянып, Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты карар бирә:

1. 2023 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегендә күпфатирлы йортларның торак урыннары милекчеләре өчен торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын 10 процент күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче К.Р. Нәҗмиев

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044881